ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

17.11.2020 ел.

с. Майдан

№13

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын билгеләү һәм түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 2020нче елның 5нче августындагы 655нче номерлы карары нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 нче елның 1 нче октябреннән Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының айлык хезмәт хакын 1,03 тапкыр арттырырга.

2. "Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында" нигезләмәнең 3нче пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- "Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары" таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазифасы | Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары халык саны | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 16171 сум | 17510 сум |

3. Әлеге карар 2020нче елның 1нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев